ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 23 ноябреннән. № 1

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Монай авылы гражданнары җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Монай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, I-II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы тылы хезмәтчәннәреннән, көндезге уку формасы студентларыннан тыш.
2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1). Монтажниклар урамындагы юлларны ремонтлау;
2. Җир кишәрлеген ял итү зонасында ызанлау;
3). Видеокүзәтү алу һәм урнаштыру.

3. Мунай авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Монай авыл җирлеге башлыгы Р.М.Кириллов